Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районының
Карга авыл жирлеге башкарма
комитеты

Республика Татарстан
Алькеевский муниципальный район
Исполнительный комитет
Каргопольского сельского поселения

Адрес:422875
Карга авылы
Үзәк ур. 30
тел: (243) 77-8-80
эл.адр.Ramil.Mingazov@tatar.ru

Адрес :422875
с. Каргополь
ул. Центральная 30
тел: (243) 77-8-80
эл.адр.Ramil.Mingazov@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **Карар**

2021 елның 7 июне №18

Әлки муниципаль районы Карга авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 сентябрендәге «Җир салымы турында» 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Карга авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Әлки муниципаль районы Карга авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 сентябрендәге «Җир салымы турында» 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6),7) абзац өстәргә:

«6) зират, үләт базы һәм гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата оешмалар һәм учреждениеләр.»

«7) гомуми файдаланудагы мәйданнар, урамнар, бистә эчендәге юллар, скверлар, бульварлар, һәйкәлләр, су объектлары, су алу скважиналары, каты көнкүреш калдыклары полигоннары биләгән җир кишәрлекләренә карата муниципаль учреждениеләр».

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга

3.Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Әлки муниципаль районы
Карга авыл җирлеге
Советы Рәисе: Р. В Мингазов

(Печать: Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы · Республика Татарстан Алькеевский муниципальный район · ОГРН 1021605757491 · ИНН 1606000... · СОВЕТ КАРГОПОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ)